КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 ноябрь г.Казань № 1271

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. 2023 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 20 август, 761 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 20 август, 761 нче карары белән расланган Социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 25 июль, 715 нче.

3. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 2.3 пунктындагы өченче абзацыннан, 5.6 пунктындагы икенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 30 ноябрь, 1271 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы мунииипаль берәмлекләре территориясендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – социаль проект, грантлар, сайлап алуда катнашучы, субсидия) бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре, бу Тәртипнең 1.4 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Бу Тәртипнең 1.4 пунктында күрсәтелгән максатка каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Министрлык.

1.3. Субсидия Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә түбәндәге юнәлешләр буенча социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү эшчәнлеген башкару өчен сайлап алуда катнашучыга бирелә:

җәмгыятьтә коррупция алу гадәтенә карата түземсезлек формалаштыру;

хәйрия белән ихтыярилыкны үстерү, яшьләргә патриотик тәрбия бирү;

гражданлык бердәмлеген, милләтара һәм динара татулыкны ныгыту;

коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлегенең иң яхшы тәҗрибәләрен ачыклау, уңышлы социаль технологияләрне тарату;

иҗтимагый һәм сәяси проблемалар турында фикер алышканда конструктив диалогның гражданлык компетенцияләрен, күнекмәләрен һәм традицияләрен үстерү;

муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый-мәдәни киңлеген үстерү, ял итү сыйфатын яхшырту һәм мәдәни байлыклардан һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру, туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү;

актив озак яшәү өчен шартлар тудыру;

массакүләм спортны, шул исәптән физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлегенең инклюзив формаларын үстерү һәм сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру;

өстәмә белем бирүне, цифрлы аң-белем таратуны, фәнни-техник һәм сәнгать иҗатын үстерү;

халыкка өзлексез экологик белем бирү һәм аң-белем тарату системасын үстерү;

гаиләгә, аналарга, аталарга һәм балаларга ярдәм күрсәтү.

махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә һәм өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарга ярдәм күрсәтү.

1.4. Субсидия сайлап алуда катнашучыга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максаты белән бирелә.

1.5. Субсидия Министрлык тарафыннан, сайлап алуда катнашучының сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар җибәргән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявка) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

1.6. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

## II. Сайлап алуны үткәрү тәртибе

2.1. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://mert.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башланган көнгә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 4.7 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) битләр күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктлары нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата критерийларны һәм таләпләрне һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге критерийларга һәм таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 2.4 һәм 2.5 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 3.1 – 3.4 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – Килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене Килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.

Сайлап алуны үткәрү чорында сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләре, әгәр дә сорату Министрлыкка заявкалар бирү срогы тәмамлану датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча керсә, Министрлык тарафыннан сайлап алуда катнашучыларга Министрлыкка тиешле сорату кергән датадан биш эш көне эчендә электрон документ рәвешендә кергән соратуда күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки язма рәвештә кергән соратуда күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә бирелә.

2.2. Сайлап алуда катнашучы түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

сайлап алуда катнашучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен «Грант конкурсы» автомат мәгълүмат системасыннан (алга таба – «Грант конкурсы» АМС) (https://грантытатарстан.рф) файдалану;

социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү буенча тәҗрибә булу (социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү буенча кимендә бер конкурс үткәрү);

коммерциягә карамаган оешма (сәяси партия һәм хәрәкәт формасындагы оешмадан, дәүләт учреждениесе һәм муниципаль учреждениесеннән, куллану

кооперативыннан, үз-үзен җайга сала торган оешмадан, эш бирүчеләр берләшмәсеннән, кооперативлар берләшмәсеннән, сәүдә-сәнәгать палатасыннан, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләреннән, адвокатлык палатасыннан, адвокатлык берләшмәсеннән, нотариаль палатадан, дәүләт-иҗтимагый һәм иҗтимагый-дәүләт оешмасыннән (берләшмәсеннән), аларның территориаль (структур) бүлекчәләреннән (бүлекләреннән), шул исәптән аерым юридик зат булучылардан, микрофинанс оешмасыннан тыш) булу;

үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү.

2.3. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү планлаштырыла торган айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч булмау (2022 елда салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган, түләнмәгән бурыч булырга мөмкин);

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлар булмау;

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучыга башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәскә, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы расланган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмау;

бу Тәртипнең 1.4 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

2022 елда Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил

дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлар тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмау.

2.4. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түбәндәге документларны кәгазь чыгынакта кулга яки 420021, Казан шәһәре, Мәскәү урамы, 55 нче йорт адресы буенча почта аша тапшыра:

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы бирә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм тиешле сайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турындагы башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) сайлап алуда катнашучының ризалыгы бирелгән, үзенең түләү реквизитлары һәм почта адресы, электрон почта адресы күрсәтелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада булган заявка;

сайлап алуда катнашучы уставының күчермәсен;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен сайлап алуда катнашучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән алынган субсидияне тоту планын;

баш бухгалтерның эшкә алу турында сайлауда катнашучы боерыгы күчермәсен;

аның бу Тәртипнең 1.4 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормавын раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имза куелган белешмә кәгазен;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен «Грант конкурсы» АМСннан файдалану хокукын раслый торган документ күчермәсен;

социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү тәҗрибәсе булуын раслый торган документларны (конкурс үткәрү турында белдерү күчермәсен, конкурста җиңүче коммерциягә карамаган оешмалар исемлеген раслау турында конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе күчермәсен).

Сайлап алуда катнашучы үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

Россия Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча салым органы тарафыннан салым түләүченең (җыемнар түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар,

штрафлар, процентлар түләве турында бирелгән белешмә кәгазен (2022 елда салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч 300 мең сумнан артмый).

Бу пунктның унынчы – унберенче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар бер папка (том) итеп шнур белән тегелгән, һәр бите номерланган, сайлап алуда катнашучының яки тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда вәкаләтле вәкилнең (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) үз кулы белән имзасы куелган һәм мөһер сугылган булырга тиеш.

Заявкаларны кабул итү срогы башланганга кадәр Министрлыкка (шул исәптән почта элемтәсе аша) кергән заявкалар теркәлми, каралмый һәм Министрлык тарафыннан, теркәүгә алудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, кергән көнендә почта элемтәсе хезмәте аша сайлап алуда катнашучыга кире кайтарыла.

Теркәлгән заявкалар үзләренә теркәлгән документлар белән сайлап алуда катнашучыларга кире кайтарылмый һәм Министрлыкта саклана.

2.5. Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

документлар, бозып төзәтүләр, төзәтүләр, төзәтмәләр (сайлап алуда катнашучының җитәкчесе яки аңа вәкаләтле зат тарафыннан кул куелган һәм мөһер сугылган төзәтүләрдән тыш) ясамыйча, билгеләнмәгән кыскартмалар һәм ике төрле мәгънәдә аңлашыла торган формулировкалар кулланмыйча, техник чаралар ярдәмендә әзерләнергә тиеш;

документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучының җитәкчесе яки аңа вәкаләтле затның имзасы белән раслана һәм аларга мөһер сугыла.

Тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

2.6. Заявкалар кабул итү вакыты тәмамланганга кадәр сайлап алуда катнашучы ирекле рәвештә язылган гариза буенча заявканы (шул исәптән заявкага үзгәрешләр кертү һәм яңа заявка бирү максаты белән) кире алырга хокуклы.

Әгәр дә заявкалар бирү срогы чыкканга кадәр заявкага үзгәреш кертү сайлап алуда катнашучы тарафыннан яңа заявка бирү юлы белән гамәлгә ашырылса яки Министрлык тарафыннан аны кире алу турында хәбәрнамә алынса, заявкага үзгәреш кертү яки аны кире алу турындагы хәбәрнамә гамәлдә дип санала.

## III. Заявкаларны кабул итү һәм карап тикшерү

3.1. Министрлык заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срокта кергән заявканы кергән көнендә субсидия алу өчен заявкаларны теркәү журналында терки, анда заявканың керү датасын һәм вакытын һәм заявкага тәртип буенча бирелгән теркәү номерын күрсәтә һәм, заявка кулдан тапшырылган очракта, сайлап алуда катнашучыга, заявканы алу датасын һәм бирелгән теркәү номерын күрсәтеп, аны алу турында кәгазь бирә.

Заявка Министрлыкка почта элемтәсе оешмасы аша кергәндә, ул субсидия алу

өчен заявкаларны теркәү журналында заявканың Министрлыкка керү датасын һәм вакытын һәм заявкага тәртип буенча бирелгән теркәү номерын күрсәтеп теркәлә.

3.2. Заявкаларны карап тикшерү, шулай ук сайлап алуда җиңүчене билгеләү яки заявканы алудан баш тарту турында карар кабул итү максатларында, Министрлык тарафыннан заявкаларны карап тикшерү комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

Комиссия Министрлык хезмәткәрләре һәм Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкиле (вәкилләре) арасыннан төзелә һәм Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссиянең составы биш кешедән ким һәм җиде кешедән артык була алмый.

Комиссия составына комиссия рәисе, секретаре, әгъзалары керә.

Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, аның карарын раслый.

Комиссия үз утырышын әгъзаларының кимендә өчтән икесе булганда үткәрә. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм Комиссия әгъзаларының 50 проценттан артыгы аңа тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

3.3. Заявкаларны кабул итү тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Комиссия сайлап алуда катнашучының һәм аның тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 2.2, 2.3, 2.5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм сайлап алу критерийларына туры килү-килмәвен тикшерә һәм сайлап алуда җиңүчене билгеләү турында яки заявканы кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә. Заявкалар аларны теркәү журналы нигезендә заявка бирү датасы буенча тәртипкә салына.

Заявканы алудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 2.2, 2.3, 2.5 пунктларында билгеләнгән сайлап алу критерийларына һәм таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик зат урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

Заявканы алудан баш тартылган очракта, Министрлык тиешле карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә сайлап алуда катнашучыга, заявканы алудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, язма хәбәрнамә җибәрә.

Заявканы алудан баш тарту турындагы карарда заявканы алудан баш тарту сәбәпләре күрсәтелергә тиеш.

Комиссиянең сайлап алуда җиңүчене билгеләү турындагы карары Комиссия секретаре тарафыннан алып барыла торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмә, утырыш уздырылган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

Беркетмәдә Комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, утырышта катнашкан комиссия әгъзалары, карап тикшерелгән заявкалар саны, заявкаларны

карап тикшерү нәтиҗәләре, субсидия суммасы турында мәгълүмат бирелә.

3.4. Министрлык, беркетмә расланган көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия бирү турында карар кабул итә һәм түбәндәге белешмәләр бирелгән сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

гаризалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

## IV. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

4.1. Килешү субсидия алучы һәм Министрлык арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә төзелә.

Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Килешү проекты Министрлык тарафыннан Министрлыктан Килешү проекты алынган көннән биш көн эчендә субсидия алучы адресына аңа имза куюга җибәрелә.

Министрлык тарафыннан Килешүгә субсидия алучыдан аның тарафыннан имза куелган Килешү алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә имза куела.

Әгәр субсидия алучы Килешүгә бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән срокта кул куймаган булса, ул Килешү төзүдән баш тарткан дип санала.

4.2. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре;

субсидияне күчерү сроклары һәм тәртибе;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 5.1 пунктында каралган хисаплылык тапшыру тәртибе һәм сроклары;

субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү сроклары һәм формалары (кирәк булганда);

субсидияне кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

Министрлык белән субсидия алучы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип формалар нигезендә Килешүгә өстәмә килешү килешү төзү шартлары һәм тәртибе;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Министрлык тарафыннан бу Тәртипнең 4.10 пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда әлеге акчага ихтыяҗ булу яки әлеге акчага ихтыяҗ булмаганда аларны кире кайтару турында карар кабул ителгәндә, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше торган чыгымнарны

гамәлгә ашыру мөмкинлеге каралган шарт;

субсидия алучының, субсидия алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;

субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела;

бу Тәртипнең 1.2 пункты нигезендә элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка субсидияне Килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган итеп киметелгән очракта, Килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешеп булмаганда Килешүне өзү турында шартлар (2022 елда Килешүнең яңа шартларын килештерү тәртибе);

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм Килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның, 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары белән расланган юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләрнең 4 пунктында, 5 пунктының «м» пунктчасында һәм 6 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләре кебек үк шартларны шундый ук коммерциягә карамаган оешмаларга карата исәпкә алып, субсидия алучы тарафыннан социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү турында нигезләмәләр.

4.3. Субсидия алучы Килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында шартнамәләр (килешүләр) төзегәндә аларга түбәндәге шартларны кертергә тиеш:

субсидия алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү

нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;

Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән субсидия алучыдан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу турында.

4.4. Субсидия Министрлык тарафыннан Килешү төзелгән көннән 10 эш көне эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган субсидия алучының исәп-хисап яки корреспондентлык счетына акча күчерү юлы белән бирелә.

4.5. Субсидия алучы Министрлыкка субсидия алу өчен билгеләнгән түләү реквизитлары үзгәрү турында алар үзгәргән көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

4.6. Субсидия алучы субсидия акчасы керү һәм тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып барырга тиеш.

4.7. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү буенча кимендә бер конкурс үткәрү;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль проектларны гамәлгә ашыручы кимендә 70 коммерциягә карамаган оешмага грантлар бирү.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срогы – субсидия бирелгән елдан соң килә торган 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

4.8. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешенә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү керә.

4.9. Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$С = З_1 + З_2 + ... + З_n,$$

монда:

$З_1$, $З_2$, ..., $З_n$ – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга бу Тәртипнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән субсидияне тоту планы нигезендә бу Тәртипнең 1.3 пунктының икенче – унөченче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча грантлар бирүгә чыгымнар.

4.10. Субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге

акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияне бу Тәртипнең 1.4 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булган очракта, субсидия алучы, хисап финанс елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Министрлыкка мондый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, субсидия алучыдан бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, бюджет законнары нигезендә субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу яки булмау турында карар кабул итә.

Министрлык тарафыннан субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык һәм субсидия алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә өстәмә килешү төзелә.

## V. Хисап бирүгә карата таләпләр һәм контрольдә тоту

5.1. Субсидия алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган 15 еннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүләрнең бертип формаларына теркәлә торган формалар буенча кулдан тапшыру ысулы белән яки хәбәр ителә торган заказлы почта хаты итеп финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирә.

5.2. Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапка субсидия бирелә торган елга субсидия алучы эшчәнлегенең финанс планы күчермәсе теркәлә.

5.3. Субсидия алучы финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисапка Министрлыкның рәсми соравы буенча әлеге рәсми сорау алынган көннән 10 эш көне эчендә субсидия бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны җибәрә.

5.4. Бу Тәртипнең 5.2 пунктында күрсәтелгән документның күчермәсе субсидия алучы яки аның вәкаләтле заты тарафыннан таныкланырга тиеш.

5.5. Кирәк булганда Министрлык Килешүдә субсидия алучы тарафынннна өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгеләргә мөмкин.

5.6. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, ә дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен

алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.

5.7. Субсидия аны алучы тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартлары һәм тәртибе бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерү фактлары буенча ачыкланган бозулар булган һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында һәм субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисаплар, өстәмә хисаплылык (кирәк булганда) бирелмәгән очракта;

тулы күләмдә – субсидия алу өчен субсидия алучы тарафыннан дөрес (тулы) булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган очракта;

Әгәр субсидия алучы тарафыннан Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән булса, Министрлык субсидия алучыга карата штраф санкцияләрен куллану турында карар кабул итә, субсидия алучыга әлеге карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә мәҗбүри рәвештә хәбәр итә.

Штраф санкцияләре күләме (A) әлеге очракта түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$A = \left(\sum_{i=1}^{2}\left(1 - \frac{d_i}{D_i}\right) \times X\right) \times V,$$

монда:

i – бу Тәртипнең 4.7 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләре саны;

$d_i$ – субсидия бирү i нәтиҗәсенең ирешелгән күрсәткече;

$D_i$ – килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү i нәтиҗәсенең план буенча күрсәткече;

X – хисап чорының соңгы көне хәленә карата Россия Федерациясе Үзәк банкының өч йөздән бер төп ставкасына тигез булган корректирлау коэффициенты;

V – субсидия алучы тарафыннан алынган субсидия акчасының күләме.

2022 елда штраф санкцияләре кулланылмый.

2022 елда субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә Килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Министрлык, субсидия алучы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә Килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Министрлык субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечен киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.

5.8. Бу Тәртипнең 4.10 һәм 5.7 пунктларында күрсәтелгән субсидияне, субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару сроклары бозылган очракта, Министрлык субсидияне, субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару срогы чыккан көннән эш

көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

5.9. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.